| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 16.03.2026 391 **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Балалар, белем бирү, медицина объектлары, спорт учреждениеләре, күпләп һәм ваклап сату базарлары, вокзал яннарында алкогольле продукция сатуны гамәлгә ашыручы сәүдә объектларына кадәр ара чикләрен билгеләү турында» 2024 елның 26 апрелендәге 561 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән югары куркыныч чыганакларын ачыклау тәртибе турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2219 номерлы карары, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Метан һәм метанол сыеклыклары әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату урыннарын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә Алабуга шәһәр прокуратурасының күрсәтмәсен исәпкә алып, Алабуга муниципаль Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Балалар, белем бирү, медицина объектлары, спорт учреждениеләре, күпләп һәм ваклап сату базарлары, вокзал яннарында алкогольле продукция сатуны гамәлгә ашыручы сәүдә объектларына кадәр ара чикләрен билгеләү турында» 2024 елның 26 апрелендәге 561 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Балалар, белем бирү, медицина объектларыннан, спорт учреждениеләреннән, күпләп, ваклап сату базарларыннан, вокзаллардан алкогольле продукция, сыра сатыла торган сәүдә объектларыннан ераклык бер территория чигеннән икенче билгеләнгән территория белән чиктәш булган иң якын ноктадан ясалма һәм табигый киртәләрне исәпкә алмыйча, туры сызык буенча үлчәнә дип билгеләргә:».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 2AE1AA8E107BD0A6911BA308E44A8D0A
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 28.01.2025 до 23.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 391 от 16.03.2026
Инициатор согласования: Половинкина И.А. Главный специалист
Согласование инициировано: 17.03.2026 10:22

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 17.03.2026 - 10:30 | - |